МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от «15» 02.2016 № 54

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси

Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә аерым дәүләт хезмәтләре вазыйфаларында, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында булучылар, башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итү тәртибе турында, һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указының 8 пунктының “б” өлешен үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны министр урынбасары А.В. Егоровка йокләргә.

Министр Л.Р. Сафин

000159

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 15 февралендәге
54 нче номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Хәбәр Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры (алга таба – министр) исеменә язма рәвештә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә) рәвешендә элеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән формада рәсмиләштерелә Һәм министрга юллана.

3. Министр хәбәрнамәне алдан карап чыгу өчен өч эш көне дәвамында коррупция яки башка төр хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы затка (алга таба - җаваплы зат) юллый.

4. Хәбәрнамәне алдан карау барышында җаваплы зат хәбәрнамәне юллаган гражданлык хезмәткәреннән анда язылган хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга тиешле тәртиптә таләпләр юллауны оештырырга хокуклы.

5. Хәбәрнамәне алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат мотивлаштырылган нәтиҗә әзерли. Хәбәрнамә, нәтиҗә һәм алдан карау барышында алынган башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә алынганнан соңгы җиде эш көне дәвамында аның тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының дәүлүт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссиясе (алга таба — Комиссия) рәисенә тәкъдим ителә.

6. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган таләпләр юлланган очракта, хәбәрнамә, нәтиҗә Һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә

алынганнан соңгы 45 көн дәвамында Комиссия рәисенә тәкъдим ителә. Билгеләнгән вакыт дәвамлылыгы озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә арттырыла алмый.

7. Хәбәрнамә, нәтиҗә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренеә эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссиясе турындагы Нигезләмәсе нигезендә карала.

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмә

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министры
Л.Р. Сафинга

______________________________
(вазыйфасының аталышы)

______________________________

______________________________
(Ф.И. Ә.и., адрес, телефон номеры)

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында
хәбәр итү кәгазе

Миндә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган (кирәклесенең астына сызарга) шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынучанлык туугa нигез булып торучы хәлләр:______________________________________________________________

______________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларны гамәлгә ашыруга йогынты ясый торган яки
йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар:____________________________

______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки көйләү буенча тәкъдим ителә торган чаралар:_____________________________________________________

______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм әлеге хәбәрнамәне караганда мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга җыенам/җыенмыйм (кирәклесенең астына сызарга).

| ___________ | ______________ | __________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаны тутырып язу) |